**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты**

**КАРАР**

**№ 8** **20.10.2016ел**

**Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең 2017 елга һәм 2018-2019 еллар план чорына бюджет проектын әзерләү тәртибе һәм сроклары турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184 статьясының 3 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Уставы нигезендә

Карар итәм:

1. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Нуртдинов Р. Р. Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты бүлекләре, Аксубай муниципаль районы Финанс бюджет палатасы белән берлектә 2017 елның 15 ноябренә кадәр Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджеты турында 2017 елга һәм 2018-2019 еллар план чорына карар проектына материаллар әзерләргә, шул исәптән:

1) 2016 елның үткән чорында Аксубай муниципаль районының социаль-икътисади үсешенең беренчел йомгаклары һәм 2016 елда социаль-икътисади үсешнең көтелгән йомгаклары;

2) Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджетының 2016 елда көтелгән үтәлешен бәяләү;

3) Аксубай муниципаль районының 2017 елга һәм 2019 елга кадәрге чорга социаль-икътисади үсеш фаразы,

4) Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең 2017-2019 елларга бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре проекты;

5) Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең 2017-2019 елларга муниципаль эчке үзләштерүләр программасы проекты;

6) Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең муниципаль гарантияләр программасы проекты

7) муниципаль бурычның югары чиге турында мәгълүмат: 01.01.2016 ел, 31.12.2017 ел, 31.12.2018 ел, 31.12.2019 ел;

8) 2017-2019 елларга Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын (килемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты) фаразлау;

2. 2017-2019 елларга Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджетының керемнәре һәм чыгымнары фаразын билгеләү максатларында Аксубай муниципаль районының финанс бюджет палатасына тапшырырга:

1) 27.10.2016 елга кадәр Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларына җирле үзидарә органнарына Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджетына 2017-2019 елларга алар идарә иткән керемнәрнең керемнәре фаразы;

2) бюджет планлаштыру субъектларына:

Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге

25.10.2016 елга кадәр 20142016 елга чыгым йөкләмәләренең алдан реестрлары;

25.10.2016 елга кадәр 2016 елда финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән бюджет акчаларын сарыф итүгә китерә торган норматив хокукый актларның үз көчен югалтуын яки гамәлдә булуын туктатуын тану турында тәкъдимнәр;

25.10.2016 елга кадәр Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджеты хисабына 2017-2019 елларда муниципаль гарантияләр алуга алдан гаризалар;

25.10.2016 елга кадәр Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнарының бюджет классификациясенә ярашлы рәвештә 20172019 елга финанслауның чик күләмнәрен бүлү;

3. Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары булган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджетына 2017-2019 елларга үзләре идарә итә торган керемнәрнең Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджетына керүен фаразлау өчен кирәкле мәгълүматны Аксубай муниципаль районы Финанс бюджет палатасына тапшырырга тәкъдим итәргә;

4. Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты, Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджеты акчаларын баш бүлүче булып тора:

1) 23.10.2016 елга кадәр социаль өлкә муниципаль учреждениеләренең Сан үзгәрешләрен килештерергә;

2) 23.10.2016 елга кадәр социаль өлкә муниципаль учреждениеләре челтәре һәм контингентлары буенча Татарстан Республикасының тиешле министрлыкларында һәм ведомстволарында Сан күрсәткечләрен килештерергә;

3) социаль өлкә муниципаль учреждениеләре челтәрен арттыру очрагында Татарстан Республикасы башкарма органнары билгеләгән срокларда яңа муниципаль учреждениеләр ачуның максатка ярашлылыгын әзерләргә һәм Татарстан Республикасы тармак министрлыкларына һәм ведомстволарына тапшырырга.

5. Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең бухгалтерлык хисабы буенча баш белгече:

1) Аксубай муниципаль районы Финанс бюджет палатасы билгеләгән срокларда 2017-2019 елларга Аксубай муниципаль районы бюджетыннан бюджетара трансфертлар күләмен исәпләү өчен башлангыч мәгълүматларны килештерергә;

2) 25.10.2016 елга кадәр Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджеты акчаларының баш идарәчеләренә 2017-2019 елга финанслауның чик күләмнәрен җибәрергә;

3) 2016 елның 1 ноябренә кадәр Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджетының баш идарәчеләре тәкъдим иткән акчаларны Россия Федерациясе чыгымнарының бюджет классификациясенә ярашлы рәвештә 2017-2019 елга финанслауның чик күләмнәрен бүлүне карарга;

6) 15.11.2016 елга кадәр «2017 елга һәм 2018 - 2019 еллар план чорына Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге бюджеты турында»карар проекты әзерләргә;

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. Р. Нуртдиновка һәм Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең бухгалтерлык хисабы буенча баш белгече М. Г. Адиевага йөкләргә.

Яңа Ибрай авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Ф.Х.Кәбиров